ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05 июль 2019 ел № 3437

Башкарма комитетның 2014 елның 11 декабрендәге 7677 нче карары белән расланган реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2014 елның 11 декабрендәге 7677 нче карары белән (Башкарма комитетның 2015 елның 31 июлендәге 4347 нче, 2016 елның 29 июнендәге 3354 нче карарлары редакциясендә) расланган реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3.3. Муниципаль хезмәт, шулай ук идарәнең урнашу урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен, Башкарма комитет бүлмәләрендә урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә.

2) «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайты (http://www.nabchelny.ru) аша;

3) Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru/) аша;

4) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (http://www.gosuslugi.ru/) аша;

5) Башкарма комитетта (идарәдә):

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша;

язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә – почта аша кәгазьдә, электрон почта – gradoctroitel@mail.ru аша электрон рәвештә.

2) 1.4 пунктта:

- 1.4 пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль казначылыкның «Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасын алып бару тәртибен раслау турында» 2017 елның 12 маендагы 11н санлы приказы (алга таба - Федераль казначылыкның 2017 елның 12 маендагы 11н санлы приказы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 25.07.2017);

- 14 абзацта «2012 елның 20 сентябрендәге 21/8 нче» цифрларын «2017 елның 24 октябрендәге 20/8 нче» цифрларына алмаштырырга;

3) 1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

реклама конструкцияләре – щитлар, стендлар, төзелеш челтәрләре, тарттырылган җайланмалар, электрон таблолар, медиа экраннар, проекция һәм теләсә нинди өслеккә реклама

проекцияләү өчен билгеләнгән башка җиһазлар, һава шарлары, аэростатлар һәм тотрыклы территориаль урнаштырыла һәм биналарның, корылмаларның тышкы стеналарында, түбәләрендә һәм тышкы реклама тарату өчен билгеләнгән башка конструктив элементларында яки алардан читтә, шулай ук җәмәгать транспорты хәрәкәтенең тукталыш пунктларында монтажлана һәм урнаштырыла торган башка техник чаралар;

объектта реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру концепциясе – булдырылган төзелешнең тышкы архитектура йөзен саклау кирәклеген исәпкә алып һәм бина фасадларында реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру вариантлары нигезендә, конкрет объектта (бина, төзелмә, корылма янәшәсендәге җир участогында тышкы мәгълүмат чарасы урнаштырылган очракта, янәшә территориясе булган бина, төзелмә, корылма,) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының вәкаләтле органы тарафыннан эшләнгән реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проекты;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 нчы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр яки авыл җирлегендә төзелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) – муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос («Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 2 маддәсенең 2 пункты);

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның бу мәгълүматларны кертүгә нигез булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата).

Гариза әлеге Регламентка 2 нче кушымтада каралган форма буенча тутырыла.»;

4) 3.3.2 пунктта:

- «архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгына (алга таба – идарә башлыгы)» сүзләрен «Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына» сүзләренә алмаштырырга;

- өченче абзацта «идарә башлыгына җибәрелгән гариза» сүзләрен «Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына җибәрелгән гариза һәм документлар» сүзләренә алмаштырырга;

5) түбәндәге эчтәлектәге 3.3.2.1 пункт белән тулыландырырга:

«3.3.2.1. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары гаризаны һәм документларны карап тикшерә һәм карап тикшерү өчен идарә башлыгына җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: карап тикшерү өчен идарә башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар.

Процедураның срогы: гариза һәм документлар кергән көнне.»;

6) 3.5.2 пунктта:

- беренче абзацны «килешенү өчен» сүзләре белән тулыландырырга;

- өченче абзацны «килешенү өчен» сүзләре белән тулыландырырга;

7) 3.5.3 пунктта:

- беренче абзацта «имза» сүзен «килешенү» сүзенә алмаштырырга;

- бишенче абзацны «килешенү өчен» сүзләре белән тулыландырырга;

8) 3.5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.4. Идарә башлыгы муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату турында хатны, муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында карар проектын яки рөхсәт бирү турында карар проектын карап тикшерә, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату турында хатны, муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында карарны яки рөхсәт бирү турында карарны килешенә һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килешенгән һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына җибәрелгән муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату турында хат, муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында карар яки рөхсәт бирү турында карар.»;

9) түбәндәге эчтәлектәге 3.5.4.1 пункт белән тулыландырырга:

«3.5.4.1. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары бирелгән хатлар проеткын һәм карарны карап тикшерә һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату турында хатны, муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында хатны яисә рөхсәт бирү турында карарны имзалый һәм аны, алга таба гариза бирүчегә бирү өчен, идарә белгеченә җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган һәм гариза бирүчегә бирү өчен идарә белгеченә җибәрелгән муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату турында хат, муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында хат яисә рөхсәт бирү турында карар.

Процедураның срогы: алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер көн.»;

10) 5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең, шулай ук 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның яки аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Гариза бирүче Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең, шулай ук 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә), яки шул исәптән аларның хезмәткәрләренә түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запросны, комплексы запросны теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу;

Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең караларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, әлеге Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тулы күләмдә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында тапшыру яки гамәлгә ашыру каралмаган документлар яки мәгълүмат яисә эшләрне гамәлгә ашыруны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) баш тарту өчен нигезләр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту.

Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең караларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, әлеге Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тулы күләмдә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең, 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның яки аларның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тарту яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу.

Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең караларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, әлеге Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тулы күләмдә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) туктату нигезләре федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату.

Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең караларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, әлеге Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тулы күләмдә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин;

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль законның 7 маддәсендәге 1 бүлекнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәтүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.

Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең караларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, әлеге Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган КФҮгә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин.

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон төрдә Башкарма комитетка, күпфункцияле үзәккә яисә күпфункцияле үзәкне оештыручы булып исәпләнгән гавами-хокукый берәмлекнең (алга таба – КФҮне оештыручы) тиешле дәүләт хакимияте органына (җирле үзидарә органына), шулай ук 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларга бирелә.

Башкарма комитет Җитәкчесенең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять Яр Чаллы шәһәре Шәһәр Советына бирелә.

КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять әлеге КФҮ җитәкчесенә бирелә.

КФҮ карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять КФҮне оештыручыга яки Татарстан Республикасының норматив хокукый акты нигезендә вәкаләтләнгән вазыйфаи затка бирелә.

210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять әлеге оешмаларның җитәкчеләренә бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтыннан, бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан яисә Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

Әлеге Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, әлеге оешмаларның рәсми сайтларыннан, бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең, 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) хезмәткәрләренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүмат, гариза бирүче – юридик затның урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ санлы

Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең шикаять бирелә торган карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүченең Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) белән нинди нигездә килешмәвенең дәлилләре.

Гариза бирүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслаучы документлар (булганда) яисә аларның күчермәләре бирелергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлгән документлар исемлеге язып куела.

5.4. Шикаять гариза бирүче яисә аның вәкаләтле заты тарафыннан имзалана.

5.5. Шикаятьне карап тикшерү срогы – ул теркәлгән көннән башлап унбиш эш көне эчендә.

Башкарма комитетның, күпфункцияле үзәкнең, 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуыннан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта, яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылудан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә.

5.6. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерү кире кагыла.

5.7. Регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннең икенче көненнән дә соңга калмый, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон төрдә шикаятьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.8. Шикаять тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерелгән очракта, Башкарма комитет Җитәкчесе ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү һәм булдырмау максатларында кабул ителергә тиешле чараларны билгели.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән җавапта, муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган кимчелекләрне тиз арада бетерү максатында, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, КФҮ яисә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм муниципаль хезмәттән файдалану максатында гариза бирүче башкарырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.»;

11) 3 нче кушымтаны 1 нче кушымтада каралган редакциядә бәян итәргә;

12) 4 нче кушымтаны 2 нче кушымтада каралган редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Башкарма комитетның
2019 елның 5 июлендәге
3437 нче карарына
1 нче кушымта

Реклама конструкциясен урнаштыруга
һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү
буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
3 нче кушымта

Реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен рөхсәткә
реклама конструкциясе
проекты №________

Реклама конструкциясенең хуҗасы: ___________________________________________
Реклама конструкциясен урнаштыру күздә тотылган урын: _____________________________

| А4 форматы | Гариза бирү вакытына реклама конструкциясен урнаштыру күздә тотылган урынның фотографиясе (төсле) | Реклама конструкциясенең тиешле масштабта монтажлап, реклама конструкциясен урнаштыру күздә тотылган урынның фотографиясе (төсле) |
|---|---|---|

Реклама конструкциясенең хуҗасы ____________________ ____________________ «___» _____ 20___ ел
Исеме, вазыйфасы/Ф.И.А.и. имза

М.У.

КИЛЕШЕНДЕ

Реклама конструкциясе проектын
килешенүгә вәкаләтле зат ________________________ ______________________ «__» _________ 20__ ел
(Вазыйфасы, Ф.И.А.и.) Имза

М.У.

1 бит

| А4 форматы | Әлеге урынны төгәл билгеләргә мөмкинлек бирүче һәм реклама конструкциясенең урнаштыру күздә тотылган урыны күрсәтелгән урнашу схемасы | |
|---|---|---|
| | Җир участогы чикләрен һәм реклама конструкциясенең урнашу урынын күрсәтеп, шәһәрнең генераль планыннан күчермә | |

Реклама конструкциясенең хуҗасы ____________________ ____________________ «___» ______ 20___ ел
Исеме, вазыйфасы/Ф.И.А.и. имза

М.У.

2 бит

| А4 форматы | Реклама конструкциясенең конструктив сурәтләре<br>Фронталь күренеше, ян-яктан күренеше<br>(Реклама конструкциянең киселештәге проекция күренешләре, файдаланылган материалларның үлчәмнәре һәм тасвирламасы белән конструкцияне беркетүнең конструктив элементларының сурәтләре) |
|---|---|

| Реклама конструкциясенең мәгълүмат кыры характеристикасы (материал, яктырту тибы, аерым очракларда – кулланыла торган яктылык диодларының мөмкинлекләре, яктылыгы, тибы) |
| --- |

Реклама конструкциясенең хуҗасы ______________________ ___________________ «___» ______ 20___ ел

Исеме, вазыйфасы/Ф.И.А.и. имза М.У.

3 бит

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2019 елның 5 июлендәге
3437 нче карарына
2 нче кушымта

Реклама конструкциясен урнаштыруга
һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү
буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
4 нче кушымта

Гариза бирүче

Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаны, әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны теркәп, Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә

Гариза һәм документлар

Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече

Гаризаны теркәүне гамәлгә ашыра, гаризаның күчермәсен гариза бирүчегә бирә, гаризаны, документларны карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә

Кабул ителгән, теркәлгән һәм Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән гариза һәм документлар

Башкарма комитет Җитәкчесе

Гаризаны һәм документларны карап тикшерә һәм Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына җибәрә

Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына җибәрелгән гариза һәм документлар

Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары

Гаризаны һәм документларны карап тикшерә, идарә башлыгына җибәрә

Карап тикшерү өчен идарә башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар

Идарә башлыгы

Гаризаны һәм документларны карап тикшерә һәм идарә бүлеге белгеченә җибәрә

Идарә бүлеге белгеченә җибәрелгән гариза һәм документлар

Идарә бүлеге белгече

Гаризаны һәм документларны карап тикшерә, ведомствоара запрослар җибәрүне гамәлгә ашыра, түбәндәгеләрне әзерли һәм килешенү өчен идарә бүлеге башлыгына җибәрә:
- муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату турында хат проекты;
- муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында карар проекты;
- рөхсәт бирү турында карар проекты

Килешенү өчен идарә бүлеге башлыгына җибәрелгән муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату турында хат проекты, муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында карар проекты яки рөхсәт бирү турында карар проекты

Идарә бүлеге башлыгы

Экспертиза үткәрә һәм килешенү өчен идарә башлыгына түбәндәгеләрне җибәрә:
- муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату турында хат проектын;
- муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында карар проектын;
- рөхсәт бирү турында карар проектын

Килешенү өчен идарә башлыгына җибәрелгән муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату турында хат проекты, муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында карар проекты яки рөхсәт бирү турында карар проекты

Идарә башлыгы

Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату турында хатны, муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында карар проектын яки рөхсәт бирү турында карар проектын карап тикшерә, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату турында хатны, муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында карарны, рөхсәт бирү турында карарны килешенә һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына җибәрә

Килешенгән һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына җибәрелгән муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату турында хат, муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында карар, рөхсәт бирү турында карар

Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары

Хатлар проектын һәм карарны карап тикшерә, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату турында хатны, муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында хатны яисә рөхсәт бирү турында карарны имзалый һәм, алга таба гариза бирүчегә җибәрү өчен, идарә бүлеге белгеченә җибәрә

Имзаланган һәм алга таба гариза бирүчегә җибәрү өчен, Идарә белгеченә җибәрелгән муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату турында хат, муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында хат яисә рөхсәт бирү турында карар

Идарә бүлеге белгече


Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату турында хатны терки һәм гариза бирүчегә җибәрә

Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату турында хат

Идарә бүлеге белгече

Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында карарны терки һәм гариза бирүчегә җибәрә

Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында карар




Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова